# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# «КАЛМАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
# МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

26.09.2016 № 8/1

**Татарстан Рспубликасы Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «җирле референдум турында»2004 елның 25 мартындагы 23 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20, 35 статьялары, Калмаш авыл җирлеге Уставы нигезендә, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Калмаш авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе белән берлектә Калмаш авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү турында инициативаны тәкъдим итәргә.

«2016 елда яшәү урыны буенча Калмаш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 200 (ике йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 100 (йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы :

1) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

а) Гагарин урамы буенча урнашкан юлны ремонтлау - 70000 сум.

б) Зөфәр Галиев урамы буенча урнашкан юлны ремонтлау, Калмаш авылы - 19 000 сум.

в) Үзәк урамы - Совет урамы тыкрыгы юлын ремонтлау, Калмаш авылы – 19 000 сум.

г) Совет урамы Тукай урамы тыкрыгы юлын ремонтлау, Калмаш авылы - 11 400 сум.

д) Игенче авылына кергәндә юл ремонты - 11 500 сум.

2) Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, су бүлү:

- материаллар сатып алу һәм Калмаш авылында су башнясы өчен киртәләр урнаштыру - 40 000 сум.

3) Каты коммуналь калдыкларны җыю һәм транспортлау эшчәнлеген оештыру:

- Калмаш авылында каты көнкүреш калдыклары өчен контейнерлар сатып алу өчен 20 000 сум.Әлеге карарны Тукай территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.

2. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмати стендларында һәм Тукай муниципаль районы порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе Р.К. Габдуллина